# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының “Җәлил шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә 2026 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

**от 29.11.2025 ел** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьяларынигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге берәмлеге торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I һәм II төркем инвалидларыннан, өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшьтән өлкәнрәк), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәүче гражданнардан, авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан тыш, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 21.09.2022 № 647 Указы буенча мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыкларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту (материаллар сатып алу, шартнамә буенча түләү);

2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогында Җәлил урамы, Җиңүнең 30 еллыгы урамы, Әхмәдиев урамы, Урман урамы буенча тротуарлар төзү, ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогындагы «каз " күлен төзекләндерү (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

4) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогында янгын гидрантын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эшләр өчен түләү)).

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми

сайтында бастырып чыгарырга (http://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырып халыкка чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
«Җәлил шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы Башлыгы Р. Ә. Кәримов